**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ LXVII СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 2**

Мөслим «_24_» _декабрь_ 2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче ноябрь «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 1 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 нче бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче ноябрь «Физик затлар милкенә салым турында» 1 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

торак йортларга, торак йортлар өлешләренә, фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә;

мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, төгәлләнмәгән төзелеш объектларына;

составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплексларга;

гаражлар һәм машина урыннарына, шул исәптән әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннарга;

һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык каралтылары яки корылмаларга;

2) 2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;

2 процент:

һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына.

3) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы

нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

**Мөслим**
**авыл җирлеге Башлыгы** **Р.Х.Муллин**

СОВЕТ МУСЛЮМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1629001032 КПП 162901001 ОГРН 1021605558336
ТАТАРСТАН